**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**«Туймәт авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Туймәт авыл җирлеге составына керүче
Туймәт авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

11 октябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 11 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

1. Туймәт авыл җирлегендә урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.
2. Туймәт торак пунктында урам-юл челтәрен төзекләндерү (чокырларны ремонтлау), Вахитов, Совет һәм Горький урамнарында юл билгеләре кую
3. Җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.
4. Җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, авыл территорияләрен үстерү, Мәктәп урамы буенча тротуар төзү (Маяк урамы башыннан алып Абдуллин урамына кадәр) өчен проект-смета документациясен эшләү

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 393 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 201 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 201 катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге составына керүче Туймәт авылы торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2022 елда Чирмешән муниципаль районы Туймәт авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

1. Туймәт авыл җирлегендә урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

2. Туймәт торак пунктында урам-юл челтәрен төзекләндерү (чокырларны ремонтлау), Вахитов, Совет һәм Горький урамнарында юл билгеләре кую

3. Җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

4. Җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, авыл территорияләрен үстерү, Мәктәп урамы буенча тротуар төзү (Маяк урамы башыннан алып Абдуллин урамына кадәр) өчен проект-смета документациясен эшләү

3. Җыен нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Туймәт авылы, Мәктәп ур., 4 нче йорт Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә рәсми интернет сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Туймәт авыл җирлеге башлыгы** **А.Б. Кәримов**